Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**« 29 » март 2023 ел** **№ 93**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында" 2018 елның 20 декабрендәге 114 номерлы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (31.03.2019 № 116, от 19.11.2019 № 134, от 05.03.2020 №142, от 14.08.2020 №150, от 18.12.2020 №20 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1."Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында" 2018 елның 20 декабрендәге 114 номерлы нигезләмәгә (31.03.2019 № 116, от 19.11.2019 № 134, от 05.03.2020 №142, от 14.08.2020 №150, от 18.12.2020 №20 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт белән тулыландырырга:

«11) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

1.2. 20.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.3. Муниципаль хезмәткәр, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль закон һәм "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында кодекс, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла»;

1.3. 20.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.8. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль

хезмәткәрләр тапшырган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткә кергәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәүләре, алар тарафыннан "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән бурычларны үтәүләре Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»;

1.4. 20.9. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.9. Җирле хакимият башлыгы вазыйфасына контракт буенча дәгъва кылучы гражданнар һәм бу вазыйфаны биләүче зат Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыра.»;

1.5. 28.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча белән тулыландырырга:

"5) муниципаль хезмәткәрләрнең чит ил агенты статусын алуы.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

“Арча шәһәре” муниципаль
берәмлеге башлыгы в.б.,
Арча шәһәр Советы рәисе в.б. Г.Х.Нигъмәдҗанова